**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**

**Акбаш авыл җирлеге Советы**

№15 **Карар** 08 август 2018 ел

Акбаш авылы

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык (күмәк) тыңлаулар (җәмәгать тикшерүләре) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә турында**

Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясенеж Шәһәр төзелеше кодексына, 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 санлы Федераль законга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать тикшерүләре) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга (кушымта).

2.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең 2011 елның 14 декабреннән булган “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең күмәк тыңлаулар турында нигезләмәсен раслау турында”гы 23 санлы Карарын көчен югалткан дип табарга.

3. Әлеге карарны Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан махсус җайланган мәгълүмати стендта урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” Ютазы муниципаль районының www.yutaza.tatar.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар аны рәсми рәвештә халыкка игълан иткәннән соң көченә керә.

Акбаш авыл җирлеге Башлыгы: Л.Р.Тимербаева

Акбаш авыл җирлеге

Советының карарына Кушымта

08.08.2018 ел №15

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать тикшерүләре) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать тикшерүләре) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә Россия Федерациясе конституциясенә, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына, 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 санлы Федераль законга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына тәңгәл китереп эшләнде.

**1 Бүлек. Гомуми нигезләмәләр**

1статья. Төп төшенчәләр

Бу нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

**ачык тыңлаулар** – Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге сорауларны, муниципаль хокукый актларны, шулай ук федераль закончалык, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән сорауларны күмәк тикшерү юлы белән җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул итү процессында катнашуга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру формасы;

**инициатив төркем** – күмәк тыңлауда катнашуга хокукы булган гражданин яки гражданнар төркеме;

**җәмәгатьчелек вәкиле** – күмәк тыңлауларда катнашкан, каралучы сорауны тикшерүдә катнашуга хокукы булган физик зат, шул исәптән, юридик затлар, берләшмәләр вәкилләре. Җәмәгатьчелек вәкиләренә җирле үзидарә һәм дәүләт власте органнары исеменнән эш иткән яки алар эшчәнлегендә килешү нигезендә катнашкан, хезмәт вазифалары буенча күмәк тыңлауларга чыгарылган сораулар буенча карарлар кабул иткән затлар керми;

**ачык тыңлауларда катнашучылар** – җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, күмәк тыңлаулар экспертлкары, күмәк тыңлауларны уздыру буенча оештыру комитеты әгъзалары;

**чыгыш ясауга хокуклары булган күмәк тыңлауларда катнашучылар** – җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, күмәк тыңлаулар сораулары буенча чыгыш ясауга оештыру комитетына үз заявкаларын әлеге Нигезләмәнең 6 маддәсендә билгеләнгән срокларда биргән җәмәгатьчелек вәкилләре;

**оештыру комитеты** – Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге вазифаи затларыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы депутатларыннан, җәмәгатьчелек һәм гражданнарның инициатив төркемнәре вәкилләреннән торган, тигез хокуклы башлангычта формалаштырылган ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру эшләрен гамәлгә ашыручы коллегиаль орган;

**җәмәгать карап тикшерүләре** – мондый тикшерүләрдә тиешле карар мәнфәгатьләренә кагылган гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, җирле үзидарә органы һәм оешмалары  вәкаләтле затлары мәҗбүри катнашкан, иҗтимагый контроль максатларында файдаланылган, иҗтимагый әһәмияттәге сорауларны, шулай ук җирле үзидарә органнары карарлары проектларын күмәк тикшерү;

**ачык тыңлаулар эксперты** – күмәк тыңлаулар сораулары буенча махсус белемгә ия булган зат һәм бу статуста вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән зат. Эксперт язма төрдә күмәк тыңлаулар сораулары буенча рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр тапшыра һәм аларны дәлилләү өчен фикер алышуларда катнаша.

**2 статья. Ачык тыңлауларны уздыру максатлары**

Күмәк тыңлаулар түбәндәге максатларда уздырыла:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә яшәүчеләр катнашында мәҗбүри тәртиптә күмәк тыңлауларга чыгарылган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге сораулары буенча муниципаль хокукый актлар проектларын тикшерү өчен;

ачык тыңлауларга чыгарылган сораулар буенча җәмәгать фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен.

Ачык тыңлауларны әзерләү, уздыру һәм нәтиҗәләрен билгеләү ачыклык, хәбәрдарлык, иреклелек, экспертлар бәйсезлеге нигезендә үткәрелә.

**3 статья. Ачык тыңлауларга чыгарылган сораулар**

1.Ачык тыңлаулар җирле әһәмияттәге сораулар буенча үткәрелә. Күмәк тыңлаулар нәтиҗәсе җирле үзидарә органнары өчен рекомендация характерында булып тора.

2. Мәҗбүри тәртиптә күмәк тыңлауларга чыгарыла:

1) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" Уставы проекты (алга таба – Устав), шулай ук Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге"муниципаль берәмлеге Советы Карары проекты, Уставка, аны әлеге норматив хокукый актларга тәңгәл китерү өчен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яки Россия Федераиясе субекты законнары нигезләмәләрен төгәл бәян итү формасында үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында отчет;

3) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең социаль-икътисади үсеше стратегиясе проекты;

4) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре, моңа 2003 елның 6 октябреннән булган "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131 санлы Федераль законга ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеген үзгәртеп кору өчен Татарстан Ресапубликасы Ютазы муниипаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге халкының тавыш бирү юлы белән яки гражданнар җыенында ризалыгы таләп ителгән очраклар керми;

5) генераль план проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты, территорияне планлаштыру проекты, территорияне чикләү проекты, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, югарыда әйтелгән расланган документларның берсенә үзгәртүләр кертүне күздә тоткан проект, шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир участогын файдалану төренә яки капиталь төзелеш объектына, рөхсәт ителгән төзелеш объектлары параметрлары чикләреннән тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проекты, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, рөхсәт ителгән җир участокларыннан файдалану һәм капиталь төзелеш объектларының бер төрен икенчесенә үзгәртү буенча сораулар;

6) ачык сервитутларраслау сораулары;

7) җылылык белән тәэмин итү проекты схемасы;

8) федераль закончалык белән билгеләнгән башка сораулар.

3. Бу һәр сорауны төрле яклап һәм тулысынча тикшерүгә комачаулык итми икән, бер үк вакытта берничә сорау буенча күмәк тыңлаулар уздыру рөхсәт ителә.

4. Күмәк тыңлауларны оештыру һәм уздыру, башкасы Росия Федерациясе закончалыгы белән билгеләнмәсә, җирле бюджет хисабыннан финанслана.

**4 статья. Ачык тыңлауларның инициаторлары**

Күмәк тыңлаулар халык, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы (алга таба – Совет), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба – Башлык) инициативасы белән, Регламентка ярашлы уздырыла.

Ачык тыңлауларны уздыру буенча халык инициативасын 18 яшьләре тулган, ун кешедән ким булмаган гражданнар төркеме күрсәтергә мөмкин.

**2 бүлек. Ачык тыңлауларны билгеләү**

**5 статья. Ачык тыңлауларны билгеләү**

1.Халык һәм Совет инициативасы буенча уздырылган күмәк тыңлаулар Совет карары белән билгеләнә.

Башлык инициативасы буенча уздырылган күмәк тыңлаулар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Күмәк тыңлаулар Россия Федерациясе закончалыгы тарафыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен кертелгән сораулар буенча уздырыла.

2. Күмәк тыңлаулар уздыру турында халык инициативасын күрсәтү һәм инициативаны хуплап яшәүчеләр имзасын җыю өчен 10 кешедән дә ким булмаган санда инициатив төркем формалаштырыла.

Инициатив төркем Советка түбәндәгеләрне тапшыра:

- 1 санлы кушымтага ярашлы форма буенча гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле тарафыннан имза куелган, ачык тыңлаулар соравын һәм аны уздыруның мөһимлеге нигезлелеген күрсәтеп, ачык тыңлаулар билгеләүне сорап язылган гариза;

- хокукый муниципаль акт проекты (аны күмәк тыңлауларда каралуга кертү очрагында);

- максатларын һәм төп нигезләмәләрен күрсәтеп, муниципаль хокукый акт кабул итү мөһимлеге дәлиле бәян ителгән аңлатма язу (пояснительная записка);

- финанс-икътисади нигезләү (ачык тыңлауларда аны гамәлгә ашыру өстәмә матди һәм башка чыгымнар таләп иткән муниципаль хокукый актны карауга керткән очракта);

- 2 санлы кушымтага ярашлы форма буенча гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

- гражданнарның инициатив төркемен оештыру турында карар кабул ителгән җыелышның беркетмәсе;

- инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан кул куелган, кәгазь битләре санын күрсәтеп, инициатив төркем тапшырган документлар исемлеге, шулай ук муниципаль хокукый акт проекты докладчысының теркәлгән хаты (муниципаль хокукый акт проекты күмәк тыңлауларда каралуга кертелгән очракта).

Гаризага һәм беркетмәгә инициатив төркем җыелышының рәислек итүчесе (гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле) һәм секретаре тарафыннан кул куелырга тиеш.

2.2. Әгәр Советка әлеге статьяның 2.1 пунктчасында әйтелгән барлык документлар да берьюлы китерелсә, гариза тапшырылган дип санала.

2.3. Инициатив төркем тарафыннан, Советка гариза һәм анда теркәлгән документлар кергән көннән соң 30 көн эчендә, күмәк тыңлаулар уздыру инициативасын хуплаучы яшәүчеләрнең имзалары - 18 яшьләре тулган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге яшәүчеләренең, әлеге Нигезләмәнең 3 санлы кушымтага ярашлы форма буенча 150 кешедән ким булмаган затның кул имзасы - җыелырга һәм тапшырылырга тиеш.

Имзалар Советка күмәк тыңлаулар уздыру турында инициатива кертү турында гариза биргән көннән соң килгән көннән башлап җыелырга мөмкин. Имза кәгазенә кулдан язылмаган яки каләм белән язылган мәгълүматлар кертергә рөхсәт ителми. Гражданнар турында тиешле мәгълүматларда һәм аларны имза кәгазенә һәм таныклык бирелгән язмага кертелгән даталарда төзәтмәләр гражданнар һәм имза җыючылар белән алдан сөйләшенеп эшләнергә тиеш.

2.4. Совет эшче төркем булдыра һәм тапшырылган имза кәгазьләрендәге мәгълүматларны имза кәгазьләре тапшырылган көннән соң ун көн дәвамында тикшерү уздыра.

Имзаларны һәм имза кәгазьләрендәге мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча, имза, дөрес һәм яраксыз дип табылырга мөмкин. Әгәр дә бу Нигезләмәгә ярашлы аның яраксызлыгы расланмаса, ул дөрес булып тора.

Ялган имзалар, яки имзаларны җыю һәм (яки) имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибен бозып җыелган имзалар дип санала:

1) имзаларны җыю чорыннан тыш җыелган имзалар;

2) 18 яшьләре тулмаган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең имзалары;

3) имза кәгазенә үз кулларын куйган датаны күрсәтмәгән гражданнарның имзалары;

4) имза кәгазенә алар турында мәгълүмат кулдан язылмаган ысул яки каләм белән куелган имзалар;

5) гражданнар турында тиешле мәгълүматларда һәм аларны имза кәгазьләренә кертү даталарында төзәтмәләр ясалган имзалар, әгәр бу төзәтмәләр гражданнар, имзалар җыючылар белән килешенеп эшләнмәсә;

6) имзалар кәгазендәге формасы әлеге Нигезләмәнең 3 санлы кушымтасы таләпләренә туры килмәгән барлык имзалар.

Тикшерү нәтиҗәләре имзалар кәгазен тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (кушымта №4).

2.5. Советның чираттагы утырышында, имзалар кәгазе тапшырылган көннән соң 15 көнлек срокта, ачык тыңлаулар билгеләү яки түбәндәге очракларда күмәк тыңлауларны билгеләү буенча гаризаны кире кагу турында карар кабул ителә:

1) ачык тыңлауларга чыгарылган сораулар, әлеге нигезләмәнең 3 маддәсендә каралган сораулардан тыш, җирле үзидарә органы компетенциясенә кермәсә;

2) тапшырылган дөрес имзалар саны күмәк тыңлаулар уздыру турында халык инициативасын күрсәтү өчен җитәрлек булмаганда;

3) инициатива күрсәтү тәртибе сакланмаганда;

4) тикшерүгә тәкъдим ителгән муниципаль норматив хокукый акт проекты Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләренә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, башка норматив хокукый актларга туры килмәгән очракларда;

5) шундый ук сорау күтәрелгән күмәк тыңлаулар уздыру датасыннан соң бер елдан ким вакыт узганда.

2.6. Күмәк тыңлауларны билгеләү турында гаризаны кире кагу инициатив төркем тарафыннан яңадан ачык тыңлаулар билгеләү өчен, кире кагуга китергән кагыйдә бозуларны бетергән очракта, киртә булып тора алмый.

2.7. Ачык тыңлауларны билгеләү турында сорау Совет регламентына ярашлы, Совет тарафыннан карала.

2.8. Ачык тыңлауларны билгеләү турында гаризаны кире каккан очракта, Совет, эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле адресына язма дәлилле белдерүнамә җибәрә.

3. Ачык тыңлауларны билгеләгән Совет, Башлык, тыңлауларны уздыру соравы, сроклары, вакыты һәм уздыру урыны, оештыру комитеты составы, тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм күмәк тыңлауларга чыгарылган муниципаль-хокукый акт проектын тикшергәндә гражданнар катнашуы турында мәгълүматлары булган тиешле муниципаль актлар кабул итә.

Ачык тыңлауларны уздыру датасы, әгәр башкасы федераль закончалык, Устав һәм әлеге Нигезләмә белән каралмаса, күмәк тыңлауларны билгеләү турында муниципаль хокукый актларны кабул иткәннән соң 30 көннән соң билгеләнә.

**6 статья.  Ачык тыңлаулар турында мәгълүмат бирү**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүчеләргә күмәк тыңлауларны билгеләү турында мәгълүмат бирү, тикшерелүче муниципаль хокукый акт проекты беркетелеп (аны күмәк тыңлауларда карап тикшергән очракта) күмәк тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт, массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру, рәсми сайтта һәм (яки) башка мәгълүмати системаларда календарь көннәр белән исәпләгәндә, ачык тыңлауларны уздыру көненә кадәр ун көнлек срокта (әгәр башкасы федераль закончалыкта, Уставта, әлеге Нигезләмәдә каралмаса) гамәлгә ашырылырга тиеш.

1.1.Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында, Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында һәм (яки) башка мәгълүмати системаларда һәм мәгълүмати стендларда бастырыла.

Мәгълүмати стендлар яхшы күренә торган урыннарында, аларга мәгълүматтан файдалана алучылар үтә алырлык урыннарны тәэмин итү мөмкинлеген исәпкә алып, урнаштырылырга тиеш.

Мәгълүмати стендларны урнаштыру эргономика таләпләренә ярашлы тормышка ашырылырга, мәгълүматтан файдаланучы озак вакыт мәҗбүри уңайсыз позада тору мөһимлеген булдырмаслык итеп урнаштырылырга тиеш.

Мәгълүмати стендларны төрле төсләр белән оформить итү эстетик таләпләргә җавап бирергә тиеш. Мәгълүмати стендларга А4 форматы “кесәләре” урнаштырылырга мөмкин, анда информацион кәгазь битләре салына.

2. Ачык тыңлауларда яки җәмәгать карап тикшерүләрендә каралырга тиеш булган проект экспозициясен уздыру мәйданчыгы, шулай ук проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү вакыты килешү буенча күмәк тыңлауларны яки җәмәгать тикшерүләрен уздыру турында белдерүгә кертелә.

Экспозиция эше вакытында килүчеләр өчен консультацияләр, проект турында басма мәгълүмати материаллар тарату оештырыла. Экспозициягә килүчеләр тикшерелүче проектка, сорауга экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу һәм тәкъдимнәр, замечаниеләр язу өчен билгеләнгән тиешле кенәгәгә (журналга) үз тәкъдимнәрен, замечаниеләрен язма төрдә кертергә хокуклы.

Проект экспозициясендә тапшырыла:

-проект;

-проектка аңлатма язу;

-Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актларына ярашлы алынган документациянең килештерү күчермәләре;

- массакүләм мәгълүмат чарасы чыгуга караган мәгълүмат белән проект буенча күмәк тыңлауларны яки җәмәгать тикшерүләрен уздыру турында информацион белдерү публикациясе күчермәсе;

- гражданнарга тикшерелүче проект буенча мәгълүмат бирү максатында, әгәр мондый материаллар проектны әзерләүне (эшләүне) оештыручы тарафыннан тапшырылса, башка мәгълүмати һәм демонстрацион материаллар.

**3бүлек. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ УЗДЫРУ**

**7 статья. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыруны оештыру**

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүчеләр өчен уңайлы вакытта (күмәк тыңлауларны ял көннәрендә 11.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, яки эш көннәрендә 17 сәгатьтән башлап 22 сәгатьтән соңламыйча тәмамлап, үткәрергә киңәш ителә).

2. Ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге вәкаләтле органы депутатлары, Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар, гражданнарның иҗтимагый төркеме вәкилләре арасыннан 5 кешедән ким булмаган санда оештыру комитеты формалаштыра. Оештыру комитеты, формалашканнан соң өч көннән дә соң булмаган срокта, үз составыннан рәис, рәис урынбасарын һәм секретарь сайлый. Оештыру комитеты, утырышта аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, карарлар кабул итәргә хокуклы.

Оештыру ачык тыңлаулар уздырыла торган бинага, анда катнашырга теләүчеләрнең тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә тиеш.

Ачык тыңлаулар уздыру көнендә оештыру комитеты күмәк тыңлауларда катнашучыларны теркәүне оештыра.

3. Күмәк тыңлауларда оештыру комитеты рәисе рәислек итә. Рәислек итүче күмәк тыңлауларны ача, күмәк тыңлауларның соравын (сорауларын), тыңлауларны уздыру тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, үзе, секретарь һәм экспертлар белән таныштыра, тыңлауларны уздыру инициаторларын күрсәтә. Оештыру комитеты секретаре ачык тыңлаулар беркетмәсен алып бара.

4. Рәислек итүче тикшерү уздырылган мәсьәлә буенча сорауны игълан итә, һәм ачык тыңлауларны уздыру инициаторлары вәкаләт биргән затка, экспертларга, шулай ук чыгыш ясарга хокуклары булган ачык тыңлауда катнашучыларга бирә. Чыгышларның чираты оештыру комитеты тарафыннан теркәлгән заявкалар бирү чираты белән билгеләнә.

5. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар да, үзләренең рекомендацияләрен кире алырга һәм (яки) башка күмәк тыңлауларда катнашучылар алга чыгарган тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча, ачык тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге сорауны (сорауларны) хәл итү уңаеннан тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге (ачык тыңлауларда катнашучылар кире каккан тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрдән тыш) төзелә.

6. Рәислек итүче, ахыргы тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр белән документны төзегәннән соң, җирле әһәмияттәге сорауны (сорауларны) хәл итүнең ахыргы вариантын тавыш бирүгә куя. Ачык тыңлауларда карарлар ачык тавыш бирү юлы белән теркәлгән тыңлауларда катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тыңлауларда катнашучы һәрбер кеше бер тавышка ия, ул аны тәкъдим ителгән җирле әһәмияттәге сорауны хәл итүгә ризалык белдереп, каршы булып

бирә һәм тавыш  бирми кала (воздерживается). Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәдә теркәлә. Беркетмәгә ачык тыңлауларның рәисе һәм секретаре кул куя.

7. Күмәк тыңлауларның беркетмәсе нигезендә, күмәк тыңлауларны уздырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре (6 санлы кушымта) ясала, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) күмәк тыңлауларга чыгарылган сорау (сораулар);

2) күмәк тыңлауларны уздыру инициаторы;

3) ачык тыңлауларны билгеләү турында хокукый актның датасы, номеры һәм исеме һәм аны бастыру (халыкка игълан итү) датасы;

4) күмәк тыңлауларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

5) ачык тыңлауларны үткәргән оештыру комитеты;

6) күмәк тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясауга хокук алган катнашучылар турында мәгълүмат;

7) ачык тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге сорауны (сорауларны) хәл итү буенча тәкъдимнәрнең һәм рекомендацияләрнең, ачык тыңлауларда катнашучылар кире алган тәкъдимнәрдән һәм рекомендацияләрдән тыш, бердәм исемлеге.

8) җирле әһәмияттәге сорауны хәл итүнең ахыргы варианты;

9) ачык тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре.

9. Күмәк тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗә ачык тыңлауларга чыгарылган сораулар буенча карарлар кабул итү өчен җаваплы җирле үзидарә органы тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Тикшерү нәтиҗәләре мәҗбүри тәртиптә күмәк тыңлаулар инициаторларына, муниципаль берәмлек халкына ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗәне вәкаләтле җирле үзидарә органы караган көннән соң, эш көннәре булып исәпләнгән 3 көнлек срокта бастыру (халыкка игълан итү) юлы белән җиткерелә.

10. Ачык тыңлаулар турында нәтиҗә, Россия Федерациясе закончалыгы белән билгеләнгән очраклардан тыш, рекомендация характерында.

**4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК УСТАВЫ ПРОЕКТЫ, УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ, ҖИРЛЕ БЮДЖЕТ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ ТУРЫНДА ОТЧЕТ ПРОЕКТЫ, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКНЕ ҮЗГӘРТЕП КОРУ ТУРЫНДА СОРАУ, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР ГЕНЕРАЛЬ**

**ПЛАННАРЫ ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ**

**8 статья. Күмәк тыңлауларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы проектын һәм Уставка үзгәрешләр кертү турында Совет карары проектын тикшерү үзенчәлекләре**

1. Ачык тыңлауларда Устав проекты һәм Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 санлы Федераль законда һәм Уставта каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карап тикшерелә.

2. Устав проекты һәм Советның Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карары проекты Советның аны кабул итү турында сорауны карау көненә кадәр, 30 көннән дә соңламыйча алдан рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Бер үк вакытта әйтелгән проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу проекты, гражданнарын аны тикшерүдә катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча күмәк тыңлаулар билгеләү турында Совет карары бастырыла.

Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары пректы буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, һәм аны тикшерүдә гражданнар катнашуы тәртибен рәсми бастыру (халыкка игълан итү), Уставка аны әлеге норматив хокукый актларга тәңгәл китерү максатында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл күчерү формасында үзгәрешләр керткән очракта таләп ителми.

3. Устав проекты яки Совет карары проекты буенча күмәк тыңлаулар Уставта билгеләнгән срокларда уздырыла, әмма әйтелгән проектларны бастырганнан соң 10 көннән иртә түгел.

4. Устав проекты яки муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруда вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

**9 статья. Ачык тыңлауларда җирле бюджет проектын һәм аның үтәлеше буенча отчетны тикшерү үзәнчелекләре**

1. Җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында еллык отчет Россия Федерациясе Бюджет кодексында, башка федераль законнарда, Уставта, “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге”

муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында” нигезләмәдә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, ачык тыңлауларда тикшерелә.

2. Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турында отчет буенча күмәк тыңлауларны уздыруны гамәлгә ашыручы орган булып оештыру комитеты тора.

Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турында отчет буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында карар кабул итүче орган булып вәкаләтле муниципаль берәмлек органы тора.

3. Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджет үтәлеше турында отчет буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында карарлар, алар кабул ителгәннән соң 10 көн срокта бастырылып чыгарылырга тиеш.

4. Җирле бюджет проекты, җирле бюджет үтәлеше турында отчет буенча күмәк тыңлаулар җирле бюджет проекты (җирле бюджет үтәлеше турында отчет) басылып чыкканнан соң, 15 календарь көннән иртәрәк уздырылмый.

**10 статья. Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын карап тикшерү үзенчәлекләре**

Муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектларына кагылган сораулар ачык тыңлауларга 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законда, 2014 елның 28 июненнән булган “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында”гы 172 санлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып чыгарыла.

**11 статья. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турында сорауны карап тикшерү үзенчәлекләре**

1. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору соравы буенча күмәк тыңлаулар 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 санлы Федераль законның 13 статьясында каралган очракларда, әлеге Федераль законның 13 статьясы 5 өлешеннән тыш, уздырыла.

2. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турында сорау буенча ачык тыңлаулар уздыру буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

**12 статья. Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча сорауларны җәмәгать тикшерүләрендә, ачык тыңлауларда карап тикшерү үзенчәлекләре**

Расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларына, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына, территорияләрне планировкалау проектларына, территорияләрне межалау проектларына, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына, җир участогын яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалану рөхсәт ителгән төренә рөхсәт турында карар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карарлар проектларына, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, бер төрдәге рөхсәт ителгән җир участокларын һәм капиталь төзелеш объектларын икенче төргә үзгәртү сораулары шулай ук җәмәгать карап тикшерүләренә чыгарылырга мөмкин.

Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары буенча җәмәгать карап тикшерүләре, ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясында китерелгән.

Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләр генераль планнарына, шәһәр округлары генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан җәмәгать карап тикшерүләре һәм ачык тыңлаулар (алга таба – җәмәгать тыңлаулары яки күмәк тыңлаулар) муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.

Җәмәгать карап тикшерүләрен яки ачык тыңлаулар үткәргәндә, анда катнашу өчен җәмәгать тикшерүләрендә һәм күмәк тыңлауларда катнашучыларны тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатында, торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Җәмәгать карап тикшерүләрен яки күмәк тыңлауларны уздыру турында муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә игълан итү мизгеленнән башлап җәмәгать тикшереп карауларын һәм ачык тыңлауларны уздыру нәтиҗәләре турында игълан басылганга кадәр срок муниципаль берәмлек уставында һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы норматив хокукый актында билгеләнә һәм бер айдан ким һәм өч айдан артык булырга тиеш түгел.

Җирле хакимият башлыгы иҗтимагый тикшерүләр яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, түбәндәге карарны кабул итә

1) генераль план проекты белән килешү һәм аны муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органына җибәрү турында;

2) генераль план проектын кире кагу һәм аны эшләп тәмамлау өчен кире җибәрү турында.

**13 статья. Ачык сервитутларны билгеләү буенча күмәк тыңлаулар уздыру үзенчәлекләре**

1.Ачык сервитутларны билгеләү буенча күмәк тыңлауларда катнашу хокукына тыңлауларны уздыру көненә 18 яше тулган, ачык сервитут билгеләү аның территориясендә күздә тотылган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә даими яки күпчелек вакытын яшәүче һәр гражданин ия.

Гражданнарның күмәк тыңлауларда катнашуы ирекле нигездә гамәлгә ашырыла.

Ачык тыңлауларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җәмәгать берләшмәләре, барлык милек формасындагы коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар катнаша ала.

2. Күмәк тыңлаулар вәкаләтле орган яки 13 статьяның 1 пунктында әйтелгән физик һәм юридик затлар инициативасы буенча уздырыла.

Ачык тыңлауларны уздыру буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

3. Вәкаләтле орган күмәк тыңлауларны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң 7 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль актларын бастыру өчен билгеләнгән рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында аларны уздыру турында белдерү бастыра.

Иҗтимагый тыңлауларны ачу алдыннан анда катнашучыларны мәҗбүри теркәү уздырыла:

юридик зат өчен - юридик затны дәүләти теркәү мәгълүматларының тулы исемлеге;

шәхси эшмәкәр өчен – фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм гражданинны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләти теркәү мәгълүматлары.

физик зат өчен – фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы, яшәү урыны адресы.

4. Ачык тыңлаулар нәтиҗәсе беркетмә белән рәсмиләштерелә, анда аларны уздыру датасы, катнашучылар һәм анда булучылар саны, ачык тыңлаулар

рәисенең, секретаренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, чыгышларның эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелә.

Беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм аларга күмәк тыңлаулар рәисе һәм секретаре тарафыннан кул куела. Беркетмәгә ачык тыңлауларда катнашучылар исемлеге теркәлә.

5. Алда торган ачык сервитут раслау турындагы күмәк тыңлаулар нәтиҗәләре вәкаләтле орган тарафыннан тикшереп карала һәм ачык сервитут билгеләү өчен мөһим булган документларга теркәп куела.

Ачык сервитутларны билгеләү буенча күмәк тыңлаулар беркетмәләрен саклау срогы – өч ел. Ачык сервитутларны билгеләү буенча күмәк тыңлаулар беркетмәләрен саклауда җаваплы зат булып вәкаләтле орган җитәкчесе тора.

**14 статья. Ачык тыңлауларда җылылык белән тәэмин итү схемасын карап тикшерү үзенчәлекләре**

1.Җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты буенча күмәк тыңлаулар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февраленнән булган “Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында”гы 154 санлы нигезләмәсендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып уздырыла.

Кушымта № 1

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы

АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА ГАРИЗА

______ кешедән торган инициатив төркем, исемлек теркәлә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкы инициативасы буенча

________________________________________________________________________________со

равы буенча ачык тыңлаулар уздырырга тәкъдим итә.

Ачык тыңлауларны уздыру мөһимлеген дәлилләү:

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Теркәлгән документлар (фактта тапшырылган документлар күрсәтелә):

1) муниципаль хокукый акт проекты (кертелгән очракта);

2) аңлатма язу (пояснительная записка);

3) финанс-икътисади яктан дәлилләү (аны гамәлгә ашыру өстәмә матди һәм башка чыгымнар таләп иткән муниципаль-хокукый актны керткән очракта);

4) гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

5) гражданнарның инициатив төркемен булдыру турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

6) теркәлгән хат.

Гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле ______________

______________

(имза) (Ф.И.Ә.)

Гражданнарның инициатив төркеме секретаре ____________ ______________

(имза) (Ф.И.Ә.)

Кушымта № 2

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы

## ИНИЦИАТИВ ТӨРКЕМ ӘГЪЗАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

| № т/б | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм туган елы (18 яшь булганда – туган көне һәм ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт мәгълүматы, шәхесне раслаучы документның сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле
_____________(имза)                _____________(Ф.И.Ә.)

Кушымта № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

## АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ ИМЗА КӘГАЗЕ

«____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________»

соравы буенча

Без, түбәндә имза куючылар, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкы инициативасы белән түбәндәге сорау буенча ачык тыңлаулар уздыруны хуплыйбыз:

«____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________»

| № т/б | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Туган елы, 18 яше тулучының өстәмә рәвештә туган көне һәм ае | Яшәү урыны адресы | Гражданинның паспортының яки паспортын алыштыручы документының сериясе һәм номеры | Шәхси имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Имза кәгазен раслыйм:

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

(имзаларны җыйган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, гражданинның паспортының яки аны алыштыручы документының сериясе, номеры һәм документны тапшыру датасы, аны тапшырган органның исемен яки кодын күрсәтеп, яшәү урыны адресы, аның имзасы һәм кул кую датасы).

Гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле ______________ ______________

(имза) (Ф.И.Ә.)

Кушымта № 4

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

# АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ ИМЗА КӘГАЗЬЛӘРЕН ТИКШЕРУ БЕРКЕТМӘСЕ

«______________________________________________________________________
______________________________________________________________________»
соравы буенча.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советына тапшырылган, ачык тыңлаулар уздыру инициативасын хуплаган гражданнар имзаларының саны ____________________________________________.

Тикшерелгән затлар имзалары ___________, шулардан:
________________ яраксыз дип табылды, түбәндәге сәбәпләр буенча:
________________________________________________________________;
________________________________________________________________.

Яраксыз имзалар саны ______________________________.

Советка фактта тапшырылган имзалардан дөрес имзалар саны ______________ тәшкил итә.

Эшче төркем җитәкчесе ________________ ___________
(имза) (Ф.И.Ә.)

Эшче төркем әгъзалары ______________________ ___________________
(имза) (Ф.И.Ә.)

________________ ______________
(имза) (Ф.И.Ә.)

__________________________
(дата, вакыт)

Гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле
(имза) _________ (Ф.И.Ә.)________________

Гражданнарның инициатив төркеме секретаре (имза) _______
(Ф.И.Ә.)_________

Кушымта № 5

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

# АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР БЕРКЕТМӘСЕ

«____» _________ 20__ ел. № _____

___________ш.

_______________________________________________________________
инициативасы буенча күмәк тыңлаулар билгеләнде ________________________________________________ число, ай, ел ____________ № _____

(муниципаль хокукый акт)

_________________________________________________________________________

(муниципаль хокукый актның исеме)

Басылды (халыкка игълан ителде):_____________________________________________________
________________________________________________________________адресы буенча уздырылды.
____________________________________________________________________

(уздыру датасы)

Оештыру комитеты:_________________________________________________________

Катнаштылар: ______________________________________________________

Рәислек итүче: ______________________________________________

Секретарь: __________________________________________________________

Экспертлар: __________________________________________________________

Ачык тыңлауларда катнашучылар: (теркәлгән катнашучылар саны) _______________________________________________________________

Ачык тыңлауларда чыгыш ясаучы катнашучылар:
_________________________________________________________________________

(Ф.И.Ә.)

Тыңладылар:

1.___________________________________________________________________

(Ф.И.Ә.)

2. ____________________________________________________________________________
(Ф.И.Ә.)
3. ____________________________________________________________________________
(Ф.И.Ә.)

Телдән һәм язма формада кертелгән рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр саны ______________________, шул исәптән:

| № т/б | Рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр | Чыгыш ясаучы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Ачык тыңлауларда рәислек итүче ______________ ________________________
(имза) (Ф.И.Ә)

Ачык тыңлауларның секретаре________________________ ________________________
(имза) (Ф.И.Ә)

Кушымта № 6

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

# КҮМӘК ТЫҢЛАУЛАР НӘТИҖӘЛӘРЕНЕҢ ЙОМГАК ӨЛЕШЕ

"__" ___________20__ел

_______________________________________ инициативасы буенча ачык тыңлаулар _____________________________________________________________________билгеләнде

(муниципаль хокукый акт)

числодан ______№ ______ _______________________________________________________________

(муниципаль хокукый актның исеме)

Бастырылды (халыкка игълан ителде):____________________________________

_____________________________________ _________________________________

адресы буенча үткәрелде

(үткәрү датасы)

Ачык тыңлауларга чыгарылган сорау (сораулар)______________________________

Ачык тыңлауларны уздыру инициаторы ______________________________________

Ачык тыңлауларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны______________________________

Ачык тыңлауларны уздырган оештыру комитеты____________________________________

Ачык тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясауга хокук алганнар турында мәгълүмат _______________________________________________________

Күмәк тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге сорауны хәл итү буенча бердәм тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр исемлеге:

| Карап тикшерүгә чыгарылган сораулар | | Экспертлар һәм катнашучылар тәкъдимнәре һәм рекомендацияләре | | Тәкъдимнәр һәм рекомендациләр (кертелде, хупланд | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|
| № т/б | Сорау формулировка яки проект исеме | № т/б | Тәкъдимнең тексты | Экспертның, катнашучының | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Ф.И.Ә. | |
| 1 | | 1.1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| 3 | | 2.2<br>3.1<br>3.2 | | | |

Җирле әһәмияттәге сорауны хәл итүнең соңгы варианты: ______________________________

Ачык тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре:

риза ______________________ (кеше)
каршы__________________ (кеше)
тавыш бирми калдылар____________ (кеше)

Оештыру комитеты рәисе ________________________________

Оештыру комитеты секретаре _________________________________